Республика Татарстан
Совет Кавзияковского сельского
поселения Сармановского
муниципального района
ул. Советская, д. 66в,
с.Кавзияково, 423377.
Телефон: (85559) 4-47-16, факс:

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Кэужияк авыл жирлеге Советы
Совет урамы, 66в йорт,
Кэужияк авылы, 423377.
Телефон: (85559) 4-47-16, факс:

ОКПО 93068344 ОГРН 1061687002992 ИНН/КПП 1636005503/163601001

**Решение** **Карар**

**«22» ноябрь 2019г.** **№ 27**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның план чорына бюджеты турында» гы карар проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның план чорына бюджеты турында» гы карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында»гы карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:
    1. Хөснетдинов Фиргать Әхсән улы-төркем җитәкчесе
    2. Фатыйхов Шамил Миннешәех улы-төркем әгъзасы
    3. Зиатдинова Раушания Әсгать кызы-төркем әгъзасы
    4. Биляева Луиза Соббух кызы-төркем әгъзасы
    5. Салахова Гөлшат Галалетдин кызы-төркем әгъзасы
4. Карар проектына гражданнар тәкъдимнәрен, авторның исем-фамилиясе, туган елын күрсәтеп: ТР, Сарман районы, Кәүҗияк авылы, Совет урамы, 66в, т. 4-47-16 адресы буенча, эшче төркемгә җибәрергә дип билгеләргә.
5. 2019 елның 07 декабрендә 14.00 сәгатькә «Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның план

чорына бюджеты турында»гы карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

6. Эшче төркемгә 2019 елнын 12 декаберенә кадәр Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Советы Рәисе,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. А. Хөснетдинов